**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ LXIII УТЫРЫШЫ**

КАРАР № 1

Тойгелде авылы « 17 » март 2020 ел

**Тойгелде авыл җирлеге Советының**
**2018 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы «Җир салымы турында»**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы һәм Совет карарында җибәрелгән техник хата нигезендә, Тойгелде авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы «Җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасының 4 абзацын төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,1%;»

2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Тойгелде авыл җирлеге Советының 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы «Тойгелде авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 2 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Тойгелде авыл җирлеге башлыгы Минһаҗев Д.М.